| СОВЕТ БОЛЬШЕКАЙБИЦКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ КАЙБЫЧ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 31нче мае Олы Кайбыч авылы № 7

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы «Олы Кайбыч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 нчы октябрендәге 131- ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында»гы Федераль законның 15 нче статьясына үзгәреш кертү хакында»гы 2017 елның 29 нчы декабрендәге 477-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлеге Советының 2017 елның 3 нче апрелендәге «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында»гы 5 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 нче бүлекне түбәндәге эчтәлекле 98.10 пунктты белән тулыландырырга:

«98.10. Транспорт чараларының һәр тукталышында, шул исәптән социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектлары янында (торак, җәмәгать һәм җитештерү биналары, төзелмәләр һәм корылмалар, шул исәптән физкультура-спорт оешмалары, мәдәният оешмалары һәм башка оешмалар урнашкан йортларны да кертеп) ял итү урыннарында I, II төркем инвалидлары белән идарә ителә торган транспорт чараларын түләүсез парковкалау өчен, шулай ук III төркем инвалидларына Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм мондый инвалидлар яки инвалид балаларны йөртүче транспорт чараларына урыннарның 10 проценттан да ким

булмаган өлеше (кимендә 1 урын) бүлеп бирелә. Күрсәтелгән транспорт чараларында «Инвалид» билгесе куелырга тиеш. Индивидуаль файдалану өчен «Инвалид» тану билгесен бирү тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләте биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә. Парковкалар өчен күрсәтелгән урыннарны башка транспорт чаралары алырга тиеш түгел».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндүге адрес буенча (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлегенең рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе Сафин Рәмис Бәгдетдин улына йөкләргә.

Совет Рәисе,
Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Олы Кайбыч авыл
җирлеге башлыгы А.И. Рәхмәтуллин